ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июнь, 2023 ел № 25/8

Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/10 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктта:

а) беренче абзацта «энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү турында» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнар» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«-йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларының куркынычсыз эшләвен тәэмин итү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, шулай ук күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтенә кергән вентиляция һәм төтен каналларын карап тоту таләпләренә карата.»;

2) 17 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

91. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе законнар нигезендә башкарыла.

92. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүгә үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 17 бүлегенең 96 пунктында күрсәтелгән карарлар кабул ителгән яисә гамәлләр (гамәл кылмау) башкарылган контрольдәге зат хокуклы.

93. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) риза булмыйча судка шикаять бирү судка кадәр шикаять биргәннән соң гына мөмкин, моңа эшмәкәрлекне гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларга) шикаять бирү очраклары керми.

94. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

95. Шикаять контрольдәге зат тарафыннан Контроль органга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештә тапшырыла.

Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза, яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдәге зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кәгазь чыганакта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча бирелә.

96. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле кысаларында хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозылган дип санаган контрольдәге затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарларга карата;

б) контроль чаралар актларына карата;

в) контроль чаралар кысаларында контроль орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата.

97. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан карала.

98. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдәге затның үз хокукларын бозулары турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

99. Җитди сәбәп аркасында шикаять бирү срогын уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенеч язуы буенча әлеге срок Контроль орган тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

100. Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче шикаятен кире алырга мөмкин. Шул ук нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

101. Шикаятьтә Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

102. Контроль орган шикаятьне теркәгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тартуы турында.

103. Әлеге Нигезләмәнең 102 пунктында күрсәтелгән карар турындагы мәгълүмат карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

104. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарына һәм (яисә) вазыйфаи затының гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Контроль орган исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, яисә ышаныч язуы реквизитлары һәм ышаныч язуы белән шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) Шикаять биргән контрольдәге затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган дәгъвалана торган Контроль орган карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле (гамәл кылмавына) турында белешмәләр;

4) Контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән мөрәҗәгать итүченең дәлилләре. Гариза бирүче дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре.

105. Шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр, янаулар булырга тиеш түгел.

106. Шикаять бирү тиешле хокук бирелгән очракта, контрольдәге затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

107. Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан

Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең шикаять предметына караган позициясе дә теркәлергә мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең позициясенә җавап Контроль орган тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

108. Түбәндәге очракларда Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаять алган көннән алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 98 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы чыкканнан соң бирелгән булса һәм шикаять бирүгә билгеләнгән срокны үзгәртү турында үтенеч булмаса;

2) шикаять бирүгә бирелгән срокны үзгәртү турындагы үтенеч канәгатьләндерелмәсә;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза керсә;

4) шикаятьтәге сораулар буенча суд карары булса;

5) элегрәк Контроль органга шул ук контрольдәге заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән булса;

6) шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының, тормышына сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр булса;

7) элек контрольдәге затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук предмет буенча шикаятен караудан баш тарткан һәм яңа дәлилләр китерелмәгән очракта;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органга бирелсә;

9) Россия Федерациясе законнары буенча Контроль орган карарларына шикаять белдерү суд тәртибендә каралган булса.

109. 108 пунктның 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

110. Контроль органның шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче системадан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау Контроль орган җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясенең закон яисә башка саклана торган сер

турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль эшчәнлекне судка кадәр шикаять бирү системасыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

111. Шикаять Контроль орган тарафыннан аны теркәгән көннән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда күрсәтелгән срок әлеге орган тарафыннан егерме эш көненә озайтылырга мөмкин.

112. Контроль орган шикаять биргән контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорап алырга хокуклы.

Контрольдәге зат күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны сорау җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сораган вакыттан алып, алар Контроль органга тапшырылган вакытка кадәр, әмма сорау җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артык булмаган срокка туктатыла.

Контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар кермәү шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый..

113. Шикаять биргән контрольдәге заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны сорап алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

114. Кабул ителгән карарның һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы аның вазыйфаи затының карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавы) шикаять белдерелгән Контроль органга йөкләнә.

115. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм шул нигездә, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

116. Кабул ителгән карарны нигезләүне үз эченә алган контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе контрольдәге затның Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

3) 2 нче кушымтаны яңа редакциядә 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын башкаруга муниципаль контроль турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022

елның 25 февралендәге 13/11 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

66. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе законнар нигезендә башкарыла.

67. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүгә үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегенең 71 пунктында күрсәтелгән карарлар кабул ителгән яисә гамәлләр (гамәл кылмау) башкарылган контрольдәге зат хокуклы.

68. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) риза булмыйча судка шикаять бирү судка кадәр шикаять биргәннән соң гына мөмкин, моңа эшмәкәрлекне гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларга) шикаять бирү очраклары керми.

69. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

70. Шикаять контрольдәге зат тарафыннан Контроль органга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештә тапшырыла.

Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза, яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдәге зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кәгазь чыганакта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча бирелә.

71. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле кысаларында хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозылган дип санаган контрольдәге затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарларга карата;

б) контроль чаралар актларына карата;

в) контроль чаралар кысаларында контроль орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата.

72. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан карала.

73. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдәге затның үз хокукларын бозулары турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

74. Җитди сәбәп аркасында шикаять бирү срогын уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенеч язуы буенча әлеге срок Контроль орган тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

75. Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче шикаятен кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

76. Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

77. Контроль орган шикаятьне теркәгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тартуы турында.

78. Әлеге Нигезләмәнең 77 пунктында күрсәтелгән карар турындагы мәгълүмат карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

79. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарына һәм (яисә) вазыйфаи затының гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Контроль орган исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, яисә ышаныч язуы реквизитлары һәм ышаныч язуы белән шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдәге затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган дәгъвалана торган Контроль орган карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле (гамәл кылмавына) турында белешмәләр;

4) контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән мөрәҗәгать итүченең дәлилләре. Гариза бирүче дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре.

80. Шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр, янаулар булырга тиеш түгел.

81. Шикаять бирү тиешле хокук бирелгән очракта, контрольдәге затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация

системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

82. Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең шикаять предметына караган позициясе дә теркәлергә мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең позициясенә җавап Контроль орган тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

83. Түбәндәге очракларда Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаять алган көннән алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 73 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы чикканнан соң бирелгән булса һәм шикаять бирүгә билгеләнгән срокны үзгәртү турында үтенеч булмаса;

2) шикаять бирүгә бирелгән срокны үзгәртү турындагы үтенеч канәгатьләндерелмәсә;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза керсә;

4) шикаятьтәге сораулар буенча суд карары булса;

5) элегрәк Контроль органга шул ук контрольдәге заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән булса;

6) шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының, тормышына сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр булса;

7) элек контрольдәге затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук предмет буенча шикаятен караудан баш тарткан һәм яңа дәлилләр китерелмәгән очракта;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органга бирелсә;

9) Россия Федерациясе законнары буенча Контроль орган карарларына шикаять белдерү суд тәртибендә каралган булса.

84. 83 пунктның 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

85. Контроль органның шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче системадан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау Контроль орган җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясенең закон яисә башка саклана торган сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль эшчәнлекне судка кадәр шикаять бирү системасыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

86. Шикаять Контроль орган тарафыннан аны теркәгән көннән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда күрсәтелгән срок әлеге орган тарафыннан егерме эш көненә озайтылырга мөмкин.

87. Контроль орган шикаять биргән контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорап алырга хокуклы.

Контрольдәге зат күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны сорау җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сораган вакыттан алып, алар Контроль органга тапшырылган вакытка кадәр, әмма сорау җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артык булмаган срокка туктатыла.

Контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар кермәү шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый..

88. Шикаять биргән контрольдәге заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны сорап алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

89. Кабул ителгән карарның һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы аның вазыйфаи затының карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавы) шикаять белдерелгән Контроль органга йөкләнә.

90. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм шул нигездә, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

91. Кабул ителгән карарны нигезләүне үз эченә алган контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе контрольдәге затның Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын

башкаруга муниципаль контроль турында Нгезләмәгә кушымтаны 1 нче кушымта дип санарга.

3) 2 нче кушымта нигезендә 2 нче кушымта өстәргә.

3. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/12 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«6. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

96. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе законнар нигезендә башкарыла.

97. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүгә үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегенең 101 пунктында күрсәтелгән карарлар кабул ителгән яисә гамәлләр (гамәл кылмау) башкарылган контрольдәге зат хокуклы.

98. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) риза булмыйча судка шикаять бирү судка кадәр шикаять биргәннән соң гына мөмкин, моңа эшмәкәрлекне гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларга) шикаять бирү очраклары керми.

99. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

100. Шикаять контрольдәге зат тарафыннан Контроль органга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештә тапшырыла.

Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза, яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдәге зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кәгазь чыганакта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча бирелә.

101. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле кысаларында хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозылган дип санаган контрольдәге затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарларга карата;

б) контроль чаралар актларына карата;

в) контроль чаралар кысаларында контроль орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата.

102. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан карала.

103. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдәге затның үз хокукларын бозулары турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

104. Җитди сәбәп аркасында шикаять бирү срогын уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенеч язуы буенча әлеге срок Контроль орган тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

105. Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче шикаятен кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

106. Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

107 Контроль орган шикаятьне теркәгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тартуы турында.

108. Әлеге Нигезләмәнең 107 пунктында күрсәтелгән карар турындагы мәгълүмат карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

109. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарына һәм (яисә) вазыйфаи затының гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Контроль орган исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, яисә ышаныч язуы реквизитлары һәм ышаныч язуы белән шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдәге затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган дәгъвалана торган Контроль орган карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле (гамәл кылмавына) турында белешмәләр;

4) контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән мөрәҗәгать итүченең дәлилләре. Гариза бирүче дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре.

110. Шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр, янаулар булырга тиеш түгел.

111. Шикаять бирү тиешле хокук бирелгән очракта, контрольдәге затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

112. Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең шикаять предметына караган позициясе дә теркәлергә мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең позициясенә җавап Контроль орган тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

113. Түбәндәге очракларда Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаять алган көннән алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 103 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы чыкканнан соң бирелгән булса һәм шикаять бирүгә билгеләнгән срокны үзгәртү турында үтенеч булмаса;

2) шикаять бирүгә бирелгән срокны үзгәртү турындагы үтенеч канәгатьләндерелмәсә;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза керсә;

4) шикаятьтәге сораулар буенча суд карары булса;

5) элегрәк Контроль органга шул ук контрольдәге заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән булса;

6) шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының, тормышына сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр булса;

7) элек контрольдәге затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук предмет буенча шикаятен караудан баш тарткан һәм яңа дәлилләр китерелмәгән очракта;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органга бирелсә;

9) Россия Федерациясе законнары буенча Контроль орган карарларына шикаять белдерү суд тәртибендә каралган булса.

114. 113 пунктның 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

115. Контроль органның шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган

контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче системадан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау Контроль орган җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясенең закон яисә башка саклана торган сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль эшчәнлекне судка кадәр шикаять бирү системасыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

116. Шикаять Контроль орган тарафыннан аны теркәгән көннән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда күрсәтелгән срок әлеге орган тарафыннан егерме эш көненә озайтылырга мөмкин.

117. Контроль орган шикаять биргән контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорап алырга хокуклы.

Контрольдәге зат күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны сорау җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сораган вакыттан алып, алар Контроль органга тапшырылган вакытка кадәр, әмма сорау җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артык булмаган срокка туктатыла.

Контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар кермәү шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый..

118. Шикаять биргән контрольдәге заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны сорап алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

119. Кабул ителгән карарның һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы аның вазыйфаи затының карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавы) шикаять белдерелгән Контроль органга йөкләнә.

120. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм шул нигездә, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

121. Кабул ителгән карарны нигезләүне үз эченә алган контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе контрольдәге затның Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм (яисә)

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

2) 3 нче кушымта нигезендә 3 нче кушымта өстәргә.

4. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11 номерлы Карары редакциясендә), 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«6. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

69. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе законнар нигезендә башкарыла.

70. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүгә үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегенең 74 пунктында күрсәтелгән карарлар кабул ителгән яисә гамәлләр (гамәл кылмау) башкарылган контрольдәге зат хокуклы.

71. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) риза булмыйча судка шикаять бирү судка кадәр шикаять биргәннән соң гына мөмкин, моңа эшмәкәрлекне гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларга) шикаять бирү очраклары керми.

72. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

73. Шикаять контрольдәге зат тарафыннан Контроль органга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештә тапшырыла.

Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза, яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдәге зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кәгазь чыганакта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча бирелә.

74. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле кысаларында хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозылган дип санаган контрольдәге затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарларга карата;

б) контроль чаралар актларына карата;

в) контроль чаралар кысаларында контроль орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата.

75. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять  Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять  Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан карала.

76. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдәге затның үз хокукларын бозулары турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

77. Җитди сәбәп аркасында шикаять бирү срогын уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенеч язуы буенча әлеге срок Контроль орган тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

78. Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче шикаятен кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

79. Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

80. Контроль орган шикаятьне теркәгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча  түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тартуы турында.

81. Әлеге Нигезләмәнең 80 пунктында күрсәтелгән карар турындагы мәгълүмат карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

82. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарына һәм  яисә)  вазыйфаи затының гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Контроль орган исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, яисә ышаныч язуы реквизитлары һәм ышаныч язуы белән шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),  шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдәге затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин  булган дәгъвалана торган Контроль орган карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле (гамәл кылмавына) турында белешмәләр;

4) контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән мөрәҗәгать итүченең дәлилләре. Гариза бирүче дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре.

83. Шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр, янаулар булырга тиеш түгел.

84. Шикаять бирү тиешле хокук бирелгән очракта, контрольдәге затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

85. Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең шикаять предметына караган позициясе дә теркәлергә мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең позициясенә җавап Контроль орган тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

86. Түбәндәге очракларда Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаять алган көннән алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 76 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы чыкканнан соң бирелгән булса һәм шикаять бирүгә билгеләнгән срокны үзгәртү турында үтенеч булмаса;

2) шикаять бирүгә бирелгән срокны үзгәртү турындагы үтенеч канәгатьләндерелмәсә;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза керсә;

4) шикаятьтәге сораулар буенча суд карары булса;

5) элегрәк Контроль органга шул ук контрольдәге заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән булса;

6) шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының, тормышына сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр булса;

7) элек контрольдәге затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук предмет буенча шикаятен караудан баш тарткан һәм яңа дәлилләр китерелмәгән очракта;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органга бирелсә;

9) Россия Федерациясе законнары буенча Контроль орган карарларына шикаять белдерү суд тәртибендә каралган булса.

87. 86 пунктның 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

88. Контроль органның шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган

контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче системадан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау Контроль орган җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясенең закон яисә башка саклана торган сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль эшчәнлекне судка кадәр шикаять бирү системасыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

89. Шикаять Контроль орган тарафыннан аны теркәгән көннән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда күрсәтелгән срок әлеге орган тарафыннан егерме эш көненә озайтылырга мөмкин.

90. Контроль орган шикаять биргән контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорап алырга хокуклы.

Контрольдәге зат күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны сорау җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сораган вакыттан алып, алар Контроль органга тапшырылган вакытка кадәр,  әмма сорау җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артык булмаган срокка туктатыла.

Контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар кермәү шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый..

91. Шикаять биргән контрольдәге заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны сорап алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

92. Кабул ителгән карарның һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы аның вазыйфаи затының карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавы) шикаять белдерелгән Контроль органга йөкләнә.

93. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм шул нигездә, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

94. Кабул ителгән карарны нигезләүне үз эченә алган контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе контрольдәге затның Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

5. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«6. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

68. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе законнар нигезендә башкарыла.

69. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүгә үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегенең 73 пунктында күрсәтелгән карарлар кабул ителгән яисә гамәлләр (гамәл кылмау) башкарылган контрольдәге зат хокуклы.

70. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) риза булмыйча судка шикаять бирү судка кадәр шикаять биргәннән соң гына мөмкин, моңа эшмәкәрлекне гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларга) шикаять бирү очраклары керми.

71. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

72. Шикаять контрольдәге зат тарафыннан Контроль органга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон рәвештә тапшырыла.

Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза, яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдәге зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кәгазь чыганакта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча бирелә.

73. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле кысаларында хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозылган дип санаган контрольдәге затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарларга карата;

б) контроль чаралар актларына карата;

в) контроль чаралар кысаларында контроль орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата.

74. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан карала.

75. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдәге затның үз хокукларын бозулары турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

76. Җитди сәбәп аркасында шикаять бирү срогын уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенеч язуы буенча әлеге срок Контроль орган тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

77. Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче шикаятен кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

78. Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

79. Контроль орган шикаятьне теркәгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тартуы турында.

80. Әлеге Нигезләмәнең 79 пунктында күрсәтелгән карар турындагы мәгълүмат карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

81. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарына һәм (яисә) вазыйфаи затының гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Контроль орган исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, яисә ышаныч язуы реквизитлары һәм ышаныч язуы белән шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдәге затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган дәгъвалана торган Контроль орган карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле (гамәл кылмавына) турында белешмәләр;

4) контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән мөрәҗәгать итүченең дәлилләре. Гариза бирүче дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре.

82. Шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр, янаулар булырга тиеш түгел.

83. Шикаять бирү тиешле хокук бирелгән очракта, контрольдәге затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

84. Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең шикаять предметына караган позициясе дә теркәлергә мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Рәисенең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең позициясенә җавап Контроль орган тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

85. Түбәндәге очракларда Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаять алган көннән алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 75 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы чыкканнан соң бирелгән булса һәм шикаять бирүгә билгеләнгән срокны үзгәртү турында үтенеч булмаса;

2) шикаять бирүгә бирелгән срокны үзгәртү турындагы үтенеч канәгатьләндерелмәсә;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза керсә;

4) шикаятьтәге сораулар буенча суд карары булса;

5) элегрәк Контроль органга шул ук контрольдәге заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән булса;

6) шикаятьтә Контроль органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының, тормышына сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, цензурасыз яисә мыскыллаулы әйтелмәләр булса;

7) элек контрольдәге затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук предмет буенча шикаятен караудан баш тарткан һәм яңа дәлилләр китерелмәгән очракта;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органга бирелсә;

9) Россия Федерациясе законнары буенча Контроль орган карарларына шикаять белдерү суд тәртибендә каралган булса.

86. 85 пунктның 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

87. Контроль органның шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган

контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче системадан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау Контроль орган җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясенең закон яисә башка саклана торган сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль эшчәнлекне судка кадәр шикаять бирү системасыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

88. Шикаять Контроль орган тарафыннан аны теркәгән көннән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда күрсәтелгән срок әлеге орган тарафыннан егерме эш көненә озайтылырга мөмкин.

89. Контроль орган шикаять биргән контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорап алырга хокуклы.

Контрольдәге зат күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны сорау җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сораган вакыттан алып, алар Контроль органга тапшырылган вакытка кадәр, әмма сорау җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артык булмаган срокка туктатыла.

Контрольдәге заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар кермәү шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый..

90. Шикаять биргән контрольдәге заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны сорап алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

91. Кабул ителгән карарның һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы аның вазыйфаи затының карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавы) шикаять белдерелгән Контроль органга йөкләнә.

92. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм шул нигездә, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

93. Кабул ителгән карарны нигезләүне үз эченә алган контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе контрольдәге затның Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нгезләмәгә кушымтаны 1 нче кушымта дип санарга.

3) 4 нче кушымта нигезендә 2 нче кушымта өстәргә.

6. Әлеге Карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасы 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

7. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
25/8 Карарына
1 нче кушымта
29 июнь, 2023 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль торак контроле
турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен файдаланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Күпфатирлы йортта торак милекчеләре булган гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкин булган очракта) яки оешмалардан, күпфатирлы йортта торактан файдаланучы гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, дәүләт мәгълүмат системаларыннан контрольдәге затлар тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу хакында дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы адресына кергән мөрәҗәгатьләр санының алдагы аналогик чор белән чагыштырганда һәм (яки) узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда вакыт берәмлеге (ай, ай, квартал) өчен өч мәртәбә һәм аннан да күбрәк үсеше.

2. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы билгели торган тәртип, форма, сроклар һәм урнаштыу вакыты нигезендә Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч ай һәм аннан да артык ай дәвамында актуальләштерелмәве.

Шәһәр Советының
25/8 Карарына
2 нче кушымта
29 июнь, 2023 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә бердәм
җылылык белән тәэмин итүче оешма
тарафыннан җылылык белән тәэмин
итү объектларын төзү,
реконструкцияләү һәм (яки)
модернизацияләү чараларын башкаруга
муниципаль контроль турында
Ннгезләмәгә
2 нче кушымта

Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын башкаруга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен файдаланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Бер җылылык белән тәэмин итү объектында өч ай эчендә ике һәм аннан да күбрәк авария булу.

2. Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы, шулай ук бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма һәм җылылык энергиясен кулланучы арасында барлыкка килә торган каршылыклар мәсьәләләре буенча кулланучылардан өч ай эчендә ике һәм аннан да күбрәк мөрәҗәгать керү.

3. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлеген үтәмәү.

4. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлеген гамәлгә ашыруның срокларын бозу.

Шәһәр Советының
25/8 Карарына
3 нче кушымта
29 июнь, 2023 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
автомобиль транспортында, шәһәр
җир өсте электр транспортында һәм
юл хуҗалыгында муниципаль
контроль турында Ннгезләмәгә
3 нче кушымта

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау эшләрен башкарган урыннарда юл-транспорт һәлакәтләре санының узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда артыграк булуы турында мәгълүмат булу.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын карап тотудагы җитешсезлекләр аркасында юл-транспорт һәлакәтләре санынын (узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда) артуы турында мәгълүмат булу.

3. Автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен гамәлгә ашыруга карата мәҗбүри таләпләрне бозу (юл-төзелеш материаллары һәм эшләнмәләргә таләпләрне дә кертеп) факты турында мәгълүмат булу.

Шәһәр Советының
25/8 Карарына
4 нче кушымта
29 июнь, 2023 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
төзекләндерү өлкәсендә муниципаль
контроль турында Ннгезләмәгә
2 нче кушымта

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан ачыкланган контрольдәге зат тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозулар санының алдагы чор һәм (яисә) календарь елның шул чоры белән чагыштырганда бер ай эчендә ике тапкыр һәм аннан да артыграк булуы.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен бозу турында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органына гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән кергән мөрәҗәгатьләр санының алдагы аналогик чор белән чагыштырганда һәм (яки) узган календарь елының шул ук чоры белән чагыштырганда ике тапкыр һәм аннан да артыграк булуы.